РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Тюлячи **КАРАР**

« 12 » ноября 2018 № 715

2019 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын
Теләче муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән
автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе
нормативларын раслау турында

"Татарстан Республикасынын икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге" дәүләт бюджет учреждениясенең 02.10.2018 елгы 01/1639 номерлы хаты белән танышкач, "Россия Федерациясендә жирле узидарәләрне гомуми принципларда оештыру" турындагы 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законы, "Россия Федерациясе мэгарифе" турындагы 2012 нче елның 29 декабрендәге 273-ФЗ Федераль законы нигезендэ,

КАРАР:

1. 2019 елга раслау:

1.1. 2019 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын 1нче кушымта нигезендэ;

1.2. Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендэ.

2. Теләче муниципаль районының Башкарма комитеты Финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларына туры китереп финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Житәкчесенең социаль мәсьәләләре буенча урынбасары А.А. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

Житэкче И.Х. Хамидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
“12” 11 2018 ел № 715
карарына 1 нче кушымта

2019 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставка нормативының күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елга сум | автотранспорт чарасының бер чакрымына ставкасы, сум |
| КАВЗ | 114254 | 36,60 |
| ПАЗ | 114511 | 36,54 |
| ГАЗ “Газель” | 108623 | 29,95 |
| УАЗ | 108170 | 28,64 |
| FIAT | 107912 | 27,25 |
| Peuqeot Boxer | 108427 | 26,89 |
| Ford Transit | 109251 | 29,98 |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
“12” 11 2018 ел № 715
карарына 2 нче кушымта

**Гомуми белем оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәплpoints механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының хисап чорында чынлыкта үтелгән юл нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының чынлыкта үтелгән юл турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында автотранспорт чарасының хисап елы өчен чынлыкта үтелгән юл буларак кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең исәп-хисабы

2.1. Муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f_m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

кайда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f_m}$ - $m$ моделе автотранспорт чараларынын фактик пробегы, километр;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, бер километрга, сум;

$NF_{at_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны транспортта йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сум;

$M_m$ - $m$ моделе автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.